**Мәгърифәтче Бубилар истәлегенә багышланган укучыларның төбәкара укулары**

Секция: Татар халкының мәгърифәтче хатын-кызлары – рухи байлык таратучылар.

# Фәнни-тикшерү эше: Зөһрә Акчурина һәм Шәфика Гаспралыларның мәгърифәтчелек өлкәсендәге эшчәнлеге.


Эшне башкарды: Таҗиева Лилия Мансур кызы.
Фәнни җитәкче: 1 нче категорияле
татар теле һәм әдәбият укытучысы
Исмәгыйлова Лениза Мехәмәтнур кызы.
Менеделеев муниципаль районы
муниципаль бюджет белем бирү оешмасы
“Бәзәкә урта гомуми белем бирү мәктәбе”
Сыйныф: 10


**Иж-Бубый – 2014**

# 1. Кереш.

Безнең бай рухи мирасыбыз, мәгърур матбугатыбыз һәм бер үк вакытта хатын-кызларыбыз хәрәкәтендә мәңге җуелмас эз калдырган шәхесләребез бар. Тик халкыбызның гаять бай тарихлы булуын, ни кызганыч, бары соңгы елларда гына аңлый башладык шул. Тарихыбызның, андагы шәхесләрнең, шул исәптән зыялы кызларыбызның да тормыш юлларын гаять дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуы нинди аяныч нәтиҗәләргә китерде...

XX гасыр башы ... Татарның зыялы ирләре Шәрыктан килгән олы гадәтне кайтарып, хатын-кызны нинди биеклеккә куя алганнар. Әлеге фәнни эшебездә без шундый хатын –кызлардан Зөһрә һәм Шәфика Гаспралы турында язуны үзебез өчен **максат** итеп куйдык. Максатыбызны тормышка ашыру өчен эшебезнең **бурычларын** да билгеләдек:

1. Шәфика һәм Зөһрә Гаспралы турында истәлекләрне барлау, чыганаклар туплау.
2. Матбугат материаллары, истәлек язмалар, документлар белән танышу;
3. Күренекле шәхесләребезнең тормыш юлын өйрәнү;
4. Укучыларда патриотик хисләр тәрбияләү

Хезмәтебезнең **тикшерү объекты** – Шәфика һәм Зөһрә (Акчурина) Гаспралыларның шәхси тормышы, ә **тикшерү предметы** – Шәфика һәм Зөһрә(Акчурина) Гаспралыларның мәгърифәтчелек өлкәсендәге эшчәнлеге.

Эш барышында **кулланылган методлар:** эзләнү, чыганаклар анализы, синтез, күзәтү.

**Кулланылган чыганаклар.**

Эш барышында төрле чыганакларга мөрәҗәгать итәргә туры килде. Фәнни эшне башкарып чыгу өчен 4 чыганакка анализ ясалды.

Эшнең **структурасы.**

**Фәнни эшебез:**

1. **кереш**
2. **төп өлештән**
3. **йомгаклаудан**
4. **әдәбият исемлегеннән һәм**

**кушымтадан (презентация) тора**.

# 2. Төп өлеш.

Бераз үткәннәребезгә күз салыйк. 1917 елны Россиядә Романовлар тәхете җимерелгәч, татар хатын-кызлары хәрәкәте дә гаять тиз җанланып китә. Мәскәүдә яшәүче татар кызлары Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтаен уздыру тәкъдимен үк күтәреп чыгалар.

Бу мөрәҗәгать россиядә татарлар күпләп яши торган зуррак шәһәрләрнең барысына да җибәрелә һәм һәркайда хуплап каршы алына. 1917 елның 24 апрелендә Казанда Бөтенроссия мөслимәләренең беренче корылтае тантаналы шартларда үзенең эшен «Новый клуб» бинасында башлап җибәрә. Корылтайда Россия, Кавказ, Кырым, Төркестан, Польша хатын-кызларыннан делегатлар катнаша. Чакырылган 71 делегаттан тыш «дөньяда күрелмәгән бу хәлне» карар очен тагын 300 дән артык хатын-кыз килә.

Съезд ачылгач, залда утыручылар барысы да хатын-кызлар хәрәкәтенең танылган эшлеклеләре, халкына хезмәт итүне тормышының максатына әйләндергән, намус-вөҗдан эше дип санаган, әмма бу вакытта үз араларыннан мәңгелеккә күчкән Фатыйма-Фәридә Нәүрүзова белән Зөһрә Акчурина-Гаспралының якты истәлеген аягүрә басып алкышлыйлар. Съездның президиумында Исмәгыйль белән Зөһрәнең кызы - хатын-кызлар азатлыгы, тигез хокуклары өчен көрәшүче, кырым хатын-кызлрының танылган житәкчесе, мөхәррир Шәфика Гаспралы утыра[1].

Әйе, Россиядә яшәүче бөтен мөселман татар хатын-кызларының мәртәбәле форумында шундый олы хөрмәткә Зөһрә Акчурина һәм аның кызы Шәфика да бик тә лаек булалар. Шәфиканың әтисе хакында бер-ике сүз әйтеп китсәм, артык булмас төсле. Исмәгыйль Мостафа улы Гаспринский (Гаспралы) (1851-1914) җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог, нәшир. Бакчасарай шәһәре мәдрәсәсендә, Воронеж шәһәре хәрби училищесында белем ала. 1883 елдан «Тәрҗеман» исемендә гәзит чыгара башлый. Яңа ысул белән укыта торган җәдит мәдрәсәләре ачуга нигез сала һәм алар өчен дәреслекләр нәшер итә. Шуның белән төрки халыклар мәгариф системасын үзгәртеп коруга зур өлеш кертә.

Зөһрә Әсфәндияр кызы Акчуринаның ире Исмәгыйль белән бергә төрки-татар дөньясында танылган «Тәрҗеман» гәзитен чыгарудагы изге өлеше һәм Кырымда кызлар мәдрәсәсе ачып, мөселман мәдәнияте тарихында онытылмас зур хезмәт куя. Шунысын да әйгми үтә алмыйм: «Тәрҗеман» гәзите Зөһрәнең кияүгә чыкканда бирелгән придан акчасына чыга.

Зәһрәнең мәгариф, матбугат өлкәсендәге хезмәтләренә үз заманының алдынгы фикер ияләре дә зур бәя биргәннәр. Ризаэтдин Фәхретдиновның «Мәшһүр хатыннар» дип исемләнгән хезмәтендә милләтебезнең асыл заты булган Зөһрә Акчурина-Гаспринскаяга багышланган бүлек тә бар. Зөһрәнең «Тәрҗеман» газетасындагы эшчәнлеген ул болай бәяли: «Туган җире Сембер вилаятен ташлап, Кырымга

Бакчасарайга китә. Хәзинәсендәге бераз микъдар кыйммәт әйберләрен сарыф итеп матбаганың әкмалына (әзерлегенә)... гайрәт итә. «Тәрҗеман» газетасы нәшер ителә башлауга беренче хезмәтче була. Биш-алты еллар «Тәрҗеман»га язылу, эш кәгазьләрен җибәрү белән бәйле эшләрне ялгызы үзе башкара... Идел-Урал тарафында булган төрки сөйләшне Исмәгыйль бәктән күпкә яхшырак белгәнлектән, Зөһрә ханым мондый арадашлыкта мөһим хезмәткәр була... Йорт хуҗалыгын һәм балаларын да һичкемгә тапшырмый, үзе карый.»

Зөһрә Акчурина туган яклары белән дә элемтәне өзми. Бакчасарай шәһәрендә үз акчасына җәдит мәктәбе ачканнан соң, ул шундый ук ысул белән яңача укытуны Зөябаш авылында да оештырырга керешә, Зөябаш авылында җәдиди ысуллы мәдрәсә ачтыруга ирешә.

1903 елның май башында унике мең кеше яшәгән Бакчасарай шәһәренә Россиянең барлык төбәкләреннән дә тагын йөзләрчә кунак җыела. Шушы кечерәк шәһәрчеккә җир йөзенең барлык тарафларыннан меңнән артык хат һәм телеграммалар килә. Төрки-татар дөньясы шулай итеп «Тәрҗеман» газетасының чыга башлавына егерме ел тулу көнен билгеләп үтә. Зөһрә Акчурина гына бу вакытта тантана итүчеләр арасында булмый. Ул кырык көннәр чамасы элек бу дөнья белән мәңгегә хушлаша һәм Бакчасарай зиратының Миңлегәрәй хан төрбәсе каршындагы урынга җирләнә. Әмма исеме тантана итүчеләр телендә, халык телендә була. Яңа заманнар килгәнчегә хәтле аның балкышы сүнмәде, исеме телдән төшмәде.

Мөхтәрәм затлар - Исмәгыйль бәк белән Зөһрә ханымның 8 балалары була: Рифат, Шәфика, Бәһия, Ләйлә, Даниял, Нигәр, Мансур һәм Хәйдәр. Балалар зур һәм бай тарихлы гаиләдә матур тәрбия алып үсәләр. Гаиләдәге нәзәкәтле мөнәсәбәт, кирәге чыкса, үз туган телләреннән тыш гарәп, фарсы, рус, француз телләрендә иркен сөйләшә алалар.

1886 нчы елда (кайбер мәгълүматларда 1889 ел күрсәтелә) туган Шәфиканы якыннан белүчеләр, аның әле бала чагыннан ук фикерләү сәләте көчлелеген, кешеләргә карата җитди, төптән уйлаган үз фикере булганлыгын әйтми калмыйлар. Шәфиканың әдәбиятны, сәнгатьне теләсә кемне сокландырырлык нечкә сиземләвен, матур итеп сөйли белүен дә күрсәтәләр. Бу сыйфатлар аның рухи затлылыгыннан, образлырак итеп әйтсәк, «аксөяклелегеннән» килгәндер.

Мөхәррирлек белән дә кечкенәдән кызыксынуы гаҗәп түгел. Ул һәрвакыт редакциягә кереп әнисе Зөһрә ханымның бетмәс-төкәнмәс эшләренә, ягьни мәкаләләрне уку, төзәтү, авторларга хатлар язу, почтаны карау - барлау һ.б. мәшәкатьләре эчендә кайный, булыша.

XX гасыр башында татар халкы арасында җәдитчелек, ягьниевропача белемгә йөз белән борылу, кыз балалар өчен махсусһөнәр мәктәпләре, рус кызлары өчен ачылган уку йортлары программалары нигезендә уку йортлары ачу өчен көрәш җәелдерелә.Бу мәсьәләләрнең «Тәрҗеман» битләрендә даими күтәрелепкилүендә Зөһрә

ханымның тырышлыгы зур, әлбәттә. Шәфика улмәкаләләрне укый, канына сендерә. һәм шушы кызыксынулар-ның нәтиҗәсе  буларак Бакчасарайда «Галәме нисван», ягьни«Хатыннар дөньясы» (1906-1910) журналы чыга башлый. Әтисе Исмәгыйль бәй җитәкчелегендә чыккан бу журнални Шәфиканыңберенче зур җиңүе дип саныйк. Әйтеп үтик, хатын-кызлар өченмахсус журнал чыгу - ул татар матбугатының шактый җитлеккән булуына да бер дәлил. Ул - хатын-кызлар тормышында зур вакыйга, чөнки журнал аларны актив, иҗади тормыш юлына алып чыгуга җитди адым, этәргечләрнең берсе. Журнал хатын-кызларны һәр яктан мәдәниятле, һөнәрле итеп тәрбияләү идеясен алга куя. Аның битләрендә гигиена, медицина, мәгариф, балалар тәрбиясе, йорт-җир карау, аш-су, кул эшләре (моның өчен чигү, тегу үрнәкләре, өлгеләре бирелә), бизәнү серләре һ.б. буенча тормыш өчен иң кирәкле киңәшләр очратасың. Тик, ни кызганыч, журнал даими чыкмаган, ни сәбәптәндер зур өзеклекләр белән нәшер ителгән.

Шәфика 1904 елда Россияне тетрәткән сәяси вакыйгаларга житди игьтибар бирә. Аерым алганда ул үзен илнең (бу очракта Россиянең) ватанпәрвәре итеп таныта. Рус-япон сугышы башлангач та, ул Россия армиясе сугышчылары өчен күлмәкләр тегү эшен башлап җибәрә. Аның бу игелекле эше башка туганнарында да теләктәшлек таба. Кыз туганнарының аңа ярдәм йөзеннән акчалар җибәрүләре мәгълүм.

Әнисенең вафатыннан соң «Тәрҗеман»ны чыгаруда әтисенә иң эшлекле ярдәм итүче дә Шәфика була. Тик, кыз баланың шәхси тормышы да бар бит әле. Инде барыбызга билгеле - XX гасыр башында төрки (ягьни тугандаш) халыкларның егетләре, үз тормышларын, мәгариф өлкәсендә хәйран алга киткән, дөньяга ачык күз белән карый башлаган укымышлы татар кызлары белән корырга телиләр. Әзәрбайҗанлы Нәсиб бәй Усуббеков та Шәфиканы яратып, үзенә кияүгә чыгарга сорый. Матур гына гаилә төзелә. Кыз бала ире янына - Ганҗә шәһәренә күчеп килә, ике балалары - кызлары Зөһрә (исеме Шәфиканың әнисе хөрмәтенә куела) һәм уллары Нияз туа. Так гаилә тарихы озакка бармаган төсле. Алар аерылышалар. Шәфиканың өйдә хуҗабикә генә булып яшисе килми. Ул шәһәрнең атаклы мәгърифәтчеләре, алдынгы карашлы ханымнары белән таныша, мәдәният, мәгариф һәм шәфкатьлелек эшләрендә катнаша. Ул яшен ташыдай актив җәмәгать эшлеклесе булып танылa, аның тавышы шәһәрнең матбугаты битләрендә ишетелә башлый. 1908 елның 5 февралендә «Закавказская газета» да басылган «О деятельности Елизавет-польского (Гянджиской) Мусульманского благотворительного общества» дигән һ.б. мәкаләләре - моның ачык мисалы.

1917 елда аның Казан Бөтенроссия хатын-кызлары корылтаена катнашканын әйтеп үткән идек. Аңа шул ук елның 18 маенда Мәскәүдә үткәрелгән Бөтен Россия мөселманнары съездында катнашу бәхете дә тигән икән. Бу тарихи вакыигалар аңа көч бирә. Инде актив җәмәгать эшлеклесе булып танылган Шәфика корылтайлардан соң тагын да канатлана. Мәскәү съездыннан соң ук Кырымга эшкә килгән укытучы татар

кызлары -Зәйнәп Әмирханова һәм Илһамия Туктаровалар белән бергә хатын-кызлар арасында колачлы эш җәелдерелә. Бакчасарайда хатын-кызлар комитеты оештырыла. Симферополь шәһәрендә хатын-кызлар өчен И.Гаспринскии исемендә укытучылар хәзерләү мәктәбе ачыла; кыз балаларны башлангыч мәктәпләргә тарту, укый-яза белмәгәннәр арасында эшләү, газеталарга мәкаләләр язу - бу эшләр алар эшләгән эшләрнең диңгездән бер тамчысы гына.

Боларга өстәп, ул 1917 елның апрелендә Бакчасарай шәһәрендә оешкан хатын-кызлар комитеты рәисе дә, яшь Кырым республикасында хәрби отрядлар (частьләр) оештыруда башлап йөрүчеләрнең дә берсе, 1917 елның августында Кырымда мөселман хатын-кызлары Үзәк комитеты оешкач, аның да рәис урынбасары була. Шул ук елның ноябрендә Кырым милли конгрессының президиумына, 1918 елда Кырым милли парламентына сайлана.

Ләкин язмыш Шәфиканың изге омтылышларын, якты хыялларын тормышка ашыруга киртә сала. Большевиклар власте Кырымда, соңрак Кавказда ныгып, илдә дәһшәтле вәзгыять урнашканнан соң, һәрбер йогынтылы хәрәкәтләрнең, милли көчләрнең көрәш мәйданын берәм-берәм калдырып китүләре шартларында, Шәфикага да туган җиреннән аерылып китүдән башка чара калмый. Ул 1920 елда Бакуга, 1921 елда Төркиягә китәргә мәҗбүр була. Китмәгән булса, 1937, 1944 еллар фаҗигасендә исән кала алмас иде...

Төркиядә дә ул милләте өчен файдалы булырга тырыша. Кырым татар халкы язмышы белән кызыксынып, аның тарихына кагылышлы материалларны бөртекләп җыя, әтисенең архивын барлый, бай материал туплый. Әмма төп шөгыле итеп балалар тәрбиясе, укытучылык эшен сайлый.

Иҗаты һәм каһарман әшчәнлеге туган халкына багышланган Шәфика Исмәгыйль кызы Гаспралы 1975 елның 31 августында фани дөньядан китә. Шунысы куанычлы, исеме һәм хезмәтләре Кырым татар халкы тарихына җуелмас һәйкәл булып кереп калган.

# 3. Йомгаклау.

Татар хатын кызларының югары белем өчен, гыйльми эшчәнлек өчен көрәше- рухи мирасыбызның бик аз, яисә бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, әмма бик гыйбрәтле һәм бик кызыклы бер сәхифәсе дияргә була. Бу сәхифә үз эченә татар халык мәгарифе тарихында мәңге сүнмәс беренче йолдызлар белән беррәттән, язгы аҗагандай ялтырап алган меңләгән билгесез зыялы хатын-кызларыбыз язмышын үз эченә ала. Әлеге язмышлар барысы да татар халкы язмышына, мәгърифәт өчен көрәш тарихына бәйле. Шәфика һәм Зөһрә Гаспралыларның тормыш юлы моңа ачык мисал.

Эш барышында без төп **максатыбызга ирештек** -Мәгърифәтче Шәфика һәм Зөһрә Гаспралыларның тормыш юлы һәм эшчәнлеген өйрәндек.Моның өчен без Шәфика һәм Зөһрә Гаспралылар турындагы истәлекләрне барладык, чыганаклар тупладык. Һәм татарларның тормышын уңай якка үзгәртүдә әлеге шәхесләрнең өлеше зур булуына инандык.

Әлеге эзләнү эше барышында башка зыялы татар хатын-кызлары турында да бик күп мәгълүмат алдык. Өммегөлсем Акчурина- Камалова, Гайшә Богданова, Заһидә Бурнашева, Фатиха Аитова, Маһруй Мозаффария, Зәйнәп Хәсәниләрне дә онытырга хакыбыз юк безнең. Үз заманының алдынгы ирләре белән бер сафта атлаган сылу хатын –кызларыбыз безнең өчен бүгенге көндә дә күркәм өлге булып торучы шәхесләр.

## 4. Кулланылган әдәбият


1. Үтәбай-Кәрими Р. Шәфика Гаспралы-Йосыфбәйле турында // әд-Дин вә әл-әдәп. 2000. Май; Hablemitoğlu Ş., Hablemitoğlu N. Şefika Caspıralı ve Rusya'da Türk Kadin Hareketi (1893-1920). Ankara, 1998.
2. Биктимирова Т.Ә. Хәтерләрне яңартыйк.-Казан: ТФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2012.-148б. Кырым татарларының мәгърифәтче кызы Шәфика Гаспралы.
3. Биктимирова Т.Ә. Хәтерләрне яңартыйк.-Казан: ТФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2012.-148б. Татар халкының мәгрифәтче кызлары.
4. Хәмидуллин Лирон. Ак төннәр хәтере: Әдәби очерк, эссе, хатирәләр. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 224 б.)